# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлегенең Дружба авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2020 елның 12 нче ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба авылында гражданнар җыены

Карар:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә I төркем инвалидларыннан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Дружба авылы очен янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

- Ләке авыл җирлегенең Дружба авылындагы өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу;

3. . Әлеге карарны Ләке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.И.Шәрипова